2007 ел, 18 май 196

Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эшләре турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында

«Күмү һәм җирләү эшләре турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-8 нче Федераль законны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Җирләү эшләре мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләр тарафыннан түләүсез нигездә күмү буенча гарантияләнгән хезмәтләр күрсәтү, аларга әлеге күрсәтелгән хезмәтләр кыйммәтен каплау, эшләмәгән һәм пенсионер булмаган гражданнарны күмү өчен, шулай ук йөклелекнең 196 көне үткәч үле бала туган очракта, гражданнарны социаль пособие белән тәэмин итү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына ел саен Татарстан Республикасы бюджетын төзегәндә түбәндәгеләргә акча күздә тотарга:

эшләмәгән һәм пенсионер булмаган гражданнарны күмү өчен, шулай ук йөклелекнең 196 көне үткәч үле бала туган очракта, социаль пособие түләүгә;

күмү эшләре мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләргә эшләмәгән һәм пенсионер булмаган гражданнарны (шул исәптән эчке эшләр органнары тарафыннан шәхесе ачыкланмаган затларны), шулай ук йөклелекнең 196 көне үткәч үле бала туган очракта, күмү хезмәтләре күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен каплауга.

3. Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыкларына чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында закон кабул иткәнгә кадәр күмү хезмәтләре күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен билгеләүне һәм Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге, Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча региональ бүлеге белән килештерүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасының Социаль яклау министрлыгына Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге филиаллары, Казан шәһәре буенча – Татарстан Республикасы Социаль яклау министрлыгының Казан шәһәрендәге социаль яклау идарәсе һәм күмү эшләре мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган

хезмәтләр арасында эшләмәгән һәм пенсионер булмаган гражданнарны күмү өчен, шулай ук йөклелекнең 196 көне үткәч үле бала туган очракта, күмү хезмәтләрен күрсәтү һәм Татарстан Республикасы бюджетында әлеге максатлар өчен күздә тотылган ассигнованиеләр чикләрендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең кыйммәтен каплау турында шартнамәләр төзүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эшләре турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 1996 ел, 22 август, 724 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

югарыда күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турындагы нигезләмәдәге 3.3 нче пунктның 3.3.4 нче пунктчасына түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен килештерә».

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Социаль яклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры Р.Н.Миңнеханов

F:\KARAR\3570706a.doc